**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

№ 26 17.10. 2016 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл индивидуаль торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре турында »гы №18, 29.02.2016 елгы Савруш авыл советы карарын кире кагу турында**

Аксубай районы прокурорының 22.09.2016 елдагы 02-08-02-16Г номерлы протестын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты нигезендә, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты нигезендә, җир кишәрлекләренә карата шәһәр төзелеше регламентында тиешле территориаль зона чикләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектлары җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен һәм рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларын күрсәтәләр, Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегендә индивидуаль торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре турында" 29.02.2016 ел, 18 нче Савруш авыл җирлеге советының карарын гамәлдән чыгарырга
2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru
һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан бирле көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе А.Г.Кузьмин

СОВЕТ САВРУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ